| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Әлмәле авылы

27 гыйнвар 2021 ел № 5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 ел 13 мартындагы 1 номерлы карары белән расланган (№21 23.10.2018 редакциясендә), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Тәртибенә 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән тулыландырып үзгәреш кертергә:

«4) Үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә килеп җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков